**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№347**
**29.01.2020**

Шәһәр һөнәри осталык
конкурсы үткәрү турында

Башкарма комитетының 2019 елның 31 октябрендәге 5598 номерлы карары белән расланган 2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәрендә мәдәниятне үстерү муниципаль программасын үтәү йөзеннән, сәнгать белеме бирү системасының кадрлар потенциалын саклау һәм үстерү максатында,

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның мәдәният идарәсенә өстәмә белем бирү оешмалары укытучылары, концертмейстерлары һәм җитәкчеләре арасында «Осталык та, илһам да» шәһәр һөнәри осталык конкурсын (алга таба – конкурс) 2020 елның февраль-мартында үткәрергә.

2. Расларга:

1) конкурс турында нигезләмәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) конкурсны үткәрү буенча оештыру комитеты составын, 2 нче кушымтада каралганча.

3. Башкарма комитетның финанс идарәсенә конкурсны үткәрү буенча чыгымнарны финанслауга акча бүлеп бирүне 2020 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетының «Мәдәният» 0801 бүлегендә (бүлекчәсендә) каралган акчалар хисабына 150 000 (бер йөз илле мең) сум күләмендә, 3 нче кушымтада каралганча тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы И.А. Сәгыйдуллинага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев

Башкарма комитетның
2020 елның 29 гыйнварындагы
347 номерлы карарына
1 нче кушымта

Өстәмә белем бирү оешмалары
укытучылары, концертмейстерлары һәм җитәкчеләре арасында
«Осталык та, илһам да» шәһәр һөнәри осталык конкурсын үткәрү турында
нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1. Башкарма комитетның мәдәният идарәсе карамагындагы өстәмә белем бирү оешмалары укытучылары, концертмейстерлары һәм җитәкчеләре арасында «Осталык та, илһам да» шәһәр һөнәри осталык конкурсы (алга таба - конкурс) сәнгать белеме бирү системасының кадрлар потенциалына ярдәм күрсәтү максатында үткәрелә.

2. Конкурсның төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

1) Яр Чаллы шәһәре хезмәт базарында өстәмә белем бирү оешмалары укытучыларының конкурентлык сәләтен арттыру;

2) укытучылар, концертмейстерлар һәм җитәкчеләрнең квалификациясен күтәрүгә булышлык итү, аларның иҗади активлыгын арттыру;

3) социаль статусны күтәрү һәм педагог һөнәре турында уңай җәмәгать фикере формалаштыру.

## 2 бүлек. Конкурсны оештыру һәм үткәрү тәртибе

3. Конкурсны оештыру һәм үткәрү өчен, составы Башкарма комитет карары белән раслана торган оештыру комитеты төзелә.

4. Оештыру комитеты түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашыра:

1) конкурсның бурычларын һәм үткәрү тәртибен аңлата;

2) конкурста катнашучыларның заявкаларын кабул итә;

3) конкурсның читтән торып һәм урында үтә торган этапларын үткәрү графигын төзи;

4) конкурс документларын алып бара;

5) бүләкләү церемониясен оештыра.

5. Конкурс 2020 елның 1 февраленнән 15 мартына кадәр өч этапта: сайлап алу (өстәмә белем бирү оешмаларында үтә), читтән торып һәм урында түбәндәге номинацияләр буенча үткәрелә:

1) «Иң яхшы укытучы»;

2) «Иң яхшы концертмейстер»;

3) «Иң яхшы җитәкче»;

4) «Перспектива».

6. Сайлап алу этабын узган катнашучыларның заявкалары 2020 елның 2 февраленә кадәр түбәндәге адрес буенча оештыру комитетына җибәрелә: Яр Чаллы шәһәре, Е.Н. Батенчук исемендәге урам, 17 йорт (dshi@bk.ru) «Балалар сәнгать мәктәбе» МАӨББУ.

Конкурсның «Иң яхшы укытучы» һәм «Иң яхшы концертмейстер» номинацияләрендә Башкарма комитетның мәдәният идарәсе карамагындагы өстәмә белем бирү оешмаларының төп хезмәткәрләре булган, урта-махсус яки югары белемгә ия, хезмәт стажы җиде елдан ким булмаган укытучылар һәм концертмейстерлар катнаша ала. Катнашучыларның яше чикләнми.

Конкурсның «Перспектива» номинациясендә Башкарма комитетның мәдәният идарәсе карамагындагы өстәмә белем бирү оешмаларының төп хезмәткәрләре булган, 30 яшькә кадәрге, урта-махсус яки югары белемгә ия, хезмәт стажы җиде елдан ким булмаган укытучылар, концертмейстерлар катнаша ала.

Конкурсның «Иң яхшы җитәкче» номинациясендә Башкарма комитетның мәдәният идарәсе карамагындагы өстәмә белем бирү оешмаларының югары белемгә ия һәм әлеге вазыйфада эш стажы өч елдан ким булмаган җитәкчеләр (директорлар һәм укыту-тәрбия эшләре буенча директор урынбасарлары) катнаша ала.

7. Конкурста катнашучы читтән торып үткәрелә торган этапта катнашу өчен 2020 елның 10 февраленә кадәр оештыру комитетына, папкага җыеп, түбәндәге материалларны җибәрә:

1) җитәкченең язмача тәкъдиме, анда конкурста катнашучының соңгы 3 ел дәвамында һөнәри үсешенең мөһим этапларын тасвирларга кирәк. Тәкъдимнең күләме басма текстның 1 битеннән артмаска тиеш;

2) конкурста катнашучының анкетасы;

3) конкурста катнашучының соңгы өч ел өчен иҗади отчеты;

4) соңгы өч елда алган диплом һәм грамоталарның күчермәләре;

5) электрон йөрткечтәге фотографияләр (портрет, эш моментлары);

6) конкурста катнашучының һөнәри осталыгын характерлый торган башка материаллар, (чара сценарийлары, методик кулланмалар, афишалар, фотоколлажлар, аудио- һәм видеоматериаллар һ.б.).

8. Конкурсның урында үтә торган этабы үз эченә түбәндәге биремнәрне ала:

1) концертмейстерлар өчен:

- конкурс биремнәре;
- визит карточкасы (10 минуттан артык түгел);
- блиц - турнир;
- эш тәҗрибәсен күрсәтү (25 минуттан артык түгел):

соло башкару (яттан сөйләү), аккомпанемент;

укучылар яки коллектив белән мөстәкыйль эш;

кәгазьдән уку.

Бәяләү критерийлары: башкару осталыгы, текстны белү, сөйләм культурасы һәм эрудиция, аралашучанлык, тамаша ясый белү, эмоциональлек, артистлык, ансамбль техникасына ия булу, шулай ук җыр һәм хореография сәнгате нигезләрен, төрле уен коралларында уйнау үзенчәлекләрен белү.

2) укытучылар өчен (уен кораллары, вокал-хор, теория, сәнгать, театр, хореография бүлекләре):

- конкурс биремнәре;
- визит карточкасы (10 минуттан артык түгел);
- блиц - турнир;
- эш тәҗрибәсен күрсәтү
- ачык дәрес (25 минуттан артык түгел)
- методик кулланмаларны, эш кабинетын презентацияләү;
- педагогик ситуацияне чишү.

Бәяләү критерийлары: компетентлык, белем бирү методикасын белү, сөйләм культурасы һәм эрудиция, коммуникабельлек, нәтиҗәлелек, инновациялелек, креативлык, авторлык стиле, артистлык.

«Перспектива» номинациясендә катнашучылар өчен конкурсның урында үткәрелә торган этабының биремнәре укытучылар, концертмейстерлар, җитәкчеләр өчен булган биремнәргә тәңгәл килә.

3) җитәкчеләр (директорлар һәм укыту-тәрбия эшләре буенча директор урынбасарлары) өчен:

- конкурс биремнәре;

- визит карточкасы (10 минуттан артык түгел);
- блиц - турнир;
- эш тәҗрибәсен күрсәтү:

үз оешмасын презентацияләү;

үз оешмасының Концепциясен яклау;

- проблемалы ситуацияне чишү.

Бәяләү критерийлары: компетентлык, сөйләм культурасы һәм эрудиция, коммуникабельлек, нәтиҗәлелек, инновациялелек, креативлык, артистлык, шәхси һәм һөнәри сыйфатларны чагылдыру.

3 бүлек. Конкурска йомгак ясау һәм бүләкләү

9. Оештыру комитеты конкурста катнашучыларны 10 баллы шкала буенча конкурсның читтән торып һәм урында үткәрелә торган этапларында конкурс сынаулары йомгаклары буенча күпчелек тавыш белән бәяли.

10. Бәяләр куелганнан соң уртача балл чыгарыла һәм номинацияләр буенча җиңүчеләр билгеләнә (сәнгать төрләренә бүлмичә).

Конкурста "Гран-При" оештыру комитеты чыгышы өчен бертавыштан 10 балл куйган катнашучыга бирелә.

«I дәрәҗә лауреат» исеме 9,5 тән 9,9 га кадәр балл җыйган катнашучыларга бирелә;

«II дәрәҗә лауреат» исеме 9,0 дән 9,4 кә кадәр балл җыйган катнашучыларга бирелә;

«III дәрәҗә лауреат» исеме 8,5 тән 8,9 га кадәр балл җыйган катнашучыларга бирелә.

IV, V дәрәҗә дипломнар бирелми.

11. Конкурсның җиңүчеләрен бүләкләү 2020 елның 13 мартында «Балалар сәнгать мәктәбе» МАӨББУда үткәрелә. Гран-при ияләре һәм I, II, III дәрәҗә лауреатлар дипломнар һәм акчалата приз белән бүләкләнә.

12. Оештыру комитеты түбәндәге хокукларга ия:

1) регламент бозылган очракта, конкурста катнашучының чыгышын туктатырга;

2) беренче, икенче, өченче урыннар бирмәскә;

3) 7,5 тән 8,4 кә кадәр балл җыйган катнашучыларга кызыксындыру дипломнары һәм махсус дипломнар: «Һөнәргә тугрылык өчен», «Иҗади потенциал өчен» һ. б. бирергә.

13. Оештыру комитетының беркетмә белән рәсмиләштерелгән карары катгый, яңадан каралырга һәм шикаять бирелергә тиеш түгел.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2020 елның 29 гыйнварындагы
347 номерлы карарына
2 нче кушымта

Өстәмә белем бирү оешмалары укытучылары, концертмейстерлары һәм җитәкчеләре арасында «Осталык та, илһам да» шәһәр һөнәри осталык конкурсын әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты
составы

| Т/с | Ф.И.А.и. | Вазыйфасы |
|---|---|---|
| 1. | Хәлимов Рамил Мәрван улы | оештыру комитеты рәисе, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары |
| оештыру комитеты әгъзалары: | | |
| 2. | Кәрамиев Румил Рәүф улы | Башкарма комитетның мәдәният идарәсе башлыгы |
| 3. | Марянина Анна Вячеславовна | Башкарма комитет мәдәният идарәсенең баш белгече |
| 4. | Борознова Нэля Солтан кызы | Яр Чаллы шәһәренең «Балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе директоры |
| 5. | Смышляева Ирина Юрьевна | мәдәният хезмәткәрләре профсоюзының шәһәр комитеты рәисе (килешү буенча). |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2020 елның 29 гыйнварындагы
347 номерлы карарына
3 нче кушымта

Өстәмә белем бирү оешмалары укытучылары, концертмейстерлары һәм җитәкчеләре арасында «Осталык та, илһам да» шәһәр һөнәри осталык конкурсын әзерләү һәм үткәрү буенча чыгымнар
сметасы

| Номинация исеме | Приз фондының күләме | Хезмәткә түләү фондына күчерелгән акчалар (30,2%) | Сумма |
|---|---|---|---|
| «Иң яхшы укытучы» | | | |
| 1 дәрәҗә | 15 000 | 4 530,00 | 19 530,00 |
| 2 дәрәҗә | 10 000 | 3 020,00 | 13 020,00 |
| 3 дәрәҗә | 7 000 | 2 114,00 | 9 114,00 |
| «Иң яхшы концертмейстер» | | | |
| 1 дәрәҗә | 15 000 | 4 530,00 | 19 530,00 |
| 2 дәрәҗә | 10 000 | 3 020,00 | 13 020,00 |
| 3 дәрәҗә | 7 000 | 2 114,00 | 9 114,00 |
| «Иң яхшы җитәкче» | | | |
| 1 дәрәҗә | 15 000 | 4 530,00 | 19 530,00 |
| 2 дәрәҗә | 10 000 | 3 020,00 | 13 020,00 |
| 3 дәрәҗә | 7 000 | 2 114,00 | 9 114,00 |
| «Перспектива» | | | |
| 1 дәрәҗә | 10 000 | 3 020,00 | 13 020,00 |
| 2 дәрәҗә | 7 000 | 2 114,00 | 9 114,00 |
| 3 дәрәҗә | 5 000 | 1 510,00 | 6 510,00 |
| | | барлыгы | 143 636,00 |
| Чыгымнар исеме | | Җаваплы | Сумма |
| Типография хезмәтләре (дипломнар, афишалар, сертификатлар) | | «Балалар сәнгать мәктәбе» МАӨББУ | 1 364,00 |
| Чәчәкләр сатып алу | | | 5 000,00 |
| | | барлыгы | 6 364,00 |
| | | барысы | 150 000,00 |

Барлыгы: 150 000,00 (бер йөз илле мең) сум (ноль) тиен.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе　　　　　　　　　　　　　Г.К. Әхмәтова